Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

КАРАР №XLII-8

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 26 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 13 декабрендәге XLII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәне «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 13 декабрендәге XLII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәгә кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенә әлеге карар нигезендә Нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләрне Татарстан Республикасы буенча Россия Федераль салым хезмәтенең 18 нче районара инспекциясендә закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвен үткәрүне тәэмин итәргә вәкаләт бирергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2023 елның 26 сентябренең
XLII-8 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмәгә
кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 13 декабрендәге XLII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә.

1. 1 маддәгә түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктны өстәргә:

«8. Контроль-хисап палатасы ведомство бүләкләрен һәм аерымлык билгеләрен гамәлгә куярга, әлеге бүләкләр һәм билгеләр турындагы нигезләмәләрне, аларның тасвирламаларын һәм рәсемнәрен, бүләкләү тәртибен расларга мөмкин.»;

2. 3 маддәдә «бәйсезлек» сүзеннән соң «, ачыклык» сүзен өстәргә;

3. 4 маддәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Контроль-хисап палатасының штат саны, законнар белән йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү зарурлыгын, Контроль-хисап палатасының оештыру һәм функциональ бәйсезлеген тәэмин итү зарурлыгын исәпкә алып, районның контроль-хисап палатасы рәисе тәкъдиме буенча район Советы тарафыннан билгеләнә.»;

4. 5 маддәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Район Советы Татарстан Республикасы Хисап палатасына әлеге Нигезләмәнең 6 маддәсендә билгеләнгән квалификация таләпләренә Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатларның туры килүе турында бәяләмә сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

5. 6 маддәдә:

5.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына түбәндәге квалификация таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнә:

1) югары белем булу;

2) дәүләт, муниципаль идарә, дәүләт, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә кимендә биш ел эшләү тәҗрибәсе булу;

3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән Россия Федерациясенең бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын, конституцияне (уставны), Россия Федерациясенең тиешле субъекты законнарын һәм башка норматив хокукый актларны җайга сала торган башка норматив хокукый актларны, вазыйфаи бурычларны үтәүгә карата район Уставын һәм башка муниципаль хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы

тарафыннан расланган Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары тарафыннан контроль һәм эксперт-аналитик чаралар уздыру өчен тышкы дәүләт һәм муниципаль аудит (контроль) стандартларына карата гомуми таләпләрне белү.»;

5.2. 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгы (подданствосы) булуны йә яшәүгә рөхсәтне яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документны туктату;»;

5.2. 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) әлеге маддәнең 3 өлешендә каралган нигезләр булу.»;

6. 7 маддәдә:

6.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Контроль-хисап палатасының күрсәтмәсен (боерыкнамәсен) яисә тәкъдимен (гаризасын) үтәмәү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.»;

6.2. 5 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгы (подданствосы) булуны йә яшәүгә рөхсәтен яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документны туктату;»;

6.3. 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында»2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү;

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазыйфасын яисә муниципаль вазыйфаны биләүче контроль-хисап органының вазыйфаи заты коррупциягә каршы тору максатында 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын (низагын, каршылыгын) булдырмау яки җайга салу таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә шул очракта, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсендәге 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса.»;

7. 8 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 маддә. Контроль-хисап палатасының вәкаләтләре

1. Контроль-хисап палатасы түбәндәге төп вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) җирле бюджет акчаларының, шулай ук Россия Федерациясе законнарында

каралган очракларда башка чараларның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле бюджет проектларына экспертиза, аның күрсәткечләренең нигезлелеген тикшерү һәм анализлау;

3) җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә аудит үткәрү;

5) муниципаль милекне формалаштыру, идарә итү һәм мондый милек белән эш итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мондый милекне формалаштыруның, идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә карата аерым хокукларны да кертеп) үтәүне тикшереп тору;

6) җирле бюджет акчалары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләрне, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан җирле бюджет акчалары һәм муниципаль милектәге мөлкәт акчалары исәбеннән башкарылган алыш-бирешләр буенча башка ысуллар белән муниципаль гарантияләр бирүнең һәм җаваплылыкны үз өстенә алуның (йөкләүнең) яисә йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлештә муниципаль хокукый актлар проектларына экспертиза ясау (карау, тикшерү), җирле бюджет керемнәрен үзгәртүгә китерә торган муниципаль хокукый актлар проектларын, шулай ук муниципаль программаларны (муниципаль программалар проектларын) экспертизалау;

8) муниципаль берәмлектә бюджет процессын анализлау һәм мониторинглау, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган тайпылышларны бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

9) агымдагы финанс елында җирле бюджетның үтәлешенә оператив анализ ясау һәм аны оештыруны тикшереп тору, квартал саен җирле бюджетның үтәлеше турында, үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре хакында мәгълүматны район Советына һәм район Башлыгына тапшыру;

10) муниципаль эчке һәм тышкы бурычның торышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

11) районның стратегик планлаштыру документларында каралган район социаль-икътисадый үсеше максатларына ирешүнең тормышка ашырылуын, хәвеф-хәтәрлекләрен һәм нәтиҗәләрен районның контроль-хисап палатасы компетенциясе чикләрендә бәяләү;

12) коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән чараларда вәкаләтләр чикләрендә катнашу;

13) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, район Советының уставында һәм норматив хокукый актларында билгеләнгән тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендәге башка вәкаләтләр.

2. Контроль-хисап палатасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләр бюджетларына кергән Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчаларын файдалануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшереп тора.

3. Тышкы муниципаль финанс контроле контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, муниципаль учреждениеләргә һәм муниципаль унитар предприятиеләргә, шулай ук, әгәр алар муниципаль берәмлек милкендәге мөлкәттән файдалансалар, башка оешмаларга карата;

2) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракларда башка затларга карата.»;

8. 11 мадданең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Контроль һәм эксперт-аналитик чаралар уздыру өчен тышкы муниципаль финанс контроле стандартлары Контроль-хисап палатасы тарафыннан Россия Федерациясе Хисап палатасы раслаган гомуми таләпләр нигезендә раслана.»;

9. 12 мадданең 3 пунктында «һәм гарызнамәләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

10. 16 маддәдә:

10.1. түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктны өстәргә:

«2.1. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләре белешмә хокукый системалардан файдалану мөмкинлеге булган эш урыны, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәре белән җиһазландырылган контроль-хисап чараларында катнашучы районның контроль-хисап палатасының җаваплы вазыйфаи затларын тәэмин итәргә тиеш.»;

10.2. түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пунктны өстәргә:

«Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында»2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. »;

11. 17 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашырганда Контроль-хисап палатасына Россия Федерациясенең мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турындагы законнары, Россия Федерациясенең дәүләт һәм закон белән саклана торган башка сер турындагы законнары нигезендә муниципаль мәгълүмат системаларына аларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле даими керү мөмкинлеге бирелә.»;

12. 18 маддәдә:

12.1. 1 пунктта «аларны карау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «ачыкланган» сүзеннән соң «бюджет һәм башка» сүзләрен өстәргә;

12.2. 3 пунктта «күрсәтмә алган көннән алып бер ай эчендә» сүзләрен «күрсәтелгән күрсәтмәдә күрсәтелгән срокта яисә, әгәр срогы күрсәтелмәгән булса, аны алган көннән алып 30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга, «карау» сүзен «үтәү» сүзенә алмаштырырга;

12.3. 4 пунктта «аларга чик кую һәм кисәтү,» сүзләреннән соң «контроль-

хисап органнары тәкъдимнәрен үтәмәү,» сүзләрен өстәргә;

12.4. 7 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Күрсәтмәне үтәү срогы контроль-хисап палатасы карары буенча озайтылырга мөмкин, ләкин бер тапкырдан да артык түгел.»;

12.5. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Контроль-хисап палатасының күрсәтмәсен (боерыкнамәсен) яисә тәкъдимен (гаризасын) үтәмәү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.»;

12.6. 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Хокук саклау органнары контроль-хисап палатасына Контроль-хисап палатасына тапшырылган материаллар буенча карау барышы һәм кабул ителгән карарлар турында мәгълүмат бирергә тиеш.»;

13. 20 маддәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Контроль-хисап палатасы хезмәттәшлек һәм үзара багланышлар турында төзелгән килешүләр нигезендә контроль һәм эксперт-аналитик чаралар уздыруда катнашуга контроль, хокук саклау һәм башка органнар һәм аларның вәкилләрен, шулай ук шартнамә нигезендә аудиторлык, фәнни-тикшеренү, эксперт һәм башка учреждениеләр һәм оешмалар, аерым белгечләр, экспертлар, тәрҗемәчеләрне җәлеп итәргә хокуклы.»;

14. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 23 маддә белән тулыландырырга:

«23 маддә. Контроль-хисап палатасы вазыйфаи затларын матди һәм социаль тәэмин итү

1. Контроль-хисап палатасы вазыйфаи затларына акчалата тәэмин итү (бүләкләү), еллык түләүле отпусклар (төп һәм өстәмә), һөнәри үсеш гарантияләнә, шул исәптән өстәмә һөнәри белем алу, муниципаль берәмлек бюджеты исәбеннән тормышны һәм сәламәтлекне мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар өчен билгеләнгән матди һәм социаль тәэминатның башка чаралары.».